ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КОНОВАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423719, Республика Татарстан
Мензелинский район, с. Коноваловка, ул. Солнечная, .4А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОНОВАЛОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423719, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Коноваловка авылы,
Кояшлы урамы, д. 4А

КАРАР
Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлеге Башкарма комитеты

07.07.2025г.

№ 89

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 28.12.2021 ел № 41 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында»22.06.2019 № 796 нигезендә,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 15.06.2022 № 1081 карары белән,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 28.12.2021 ел № 41 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 3 бүлегендәге 12 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- ташламалар алу хокукыннан файдаланган түләүчеләр санының һәм ташламалар куллану өчен потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының яисә түләүчеләрнең гомуми санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана торган бирелгән ташламаларны түләүчеләрнең ихтыяҗы»;

1.2. 1 нче кушымтаның 3 бүлегендәге 12 пунктының 2 абзацында«, муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 1 нче кушымтаның 1 бүлегенең 3 пунктында «, муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М. Н. Галимҗанов